Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге составына керүче Яңа Ибрай авылында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 28 ноябре № 2

««Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яңа Ибрай авыл җирлегенең яңа Ибрай торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.2020 елда Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Яңа Ибрай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, гражданнар өчен 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына һәм җирлек торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге:

- кышкы юлларны карап тоту.
- Яна Ибрай авылы юлларына вак таш сатып алу һәм түшәү.
– Яңа Ибрай авылы эчендәге юлларны тигезләү

2) авыл территориясен төзекләндерү тәртибен раслау, аны конторольдә тоту, авыл территориясендә төзекләндерү тәртибенә нигезләнеп оештыру
   - Яңа Ибрай авылында электр яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру

3. Әлеге карарны Яңа Ибрай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында http://aksubaevo.tatar.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Ибрай авыл җирлеге башлыгы Ф.Х. Кәбиров